КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 декабрь г.Казань № 1040

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 июнь, 421 нче, 2015 ел, 15 сентябрь, 678 нче, 2016 ел, 18 февраль, 102 нче, 2017 ел, 5 июнь, 337 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү буенча комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

2.1 пунктта:

беренче абзацта «12» саннарын «11» саннарына алмаштырырга;

унөченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

4.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан күрсәткечләрне исәпләү Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурста катнашучыларны бәяләү методикасы нигезендә башкарыла (Нигезләмәгә 4 нче кушымта)»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

Нигезләмәгә 4 нче кушымтаны «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурста катнашучыларны бәяләү методикасы» өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин